КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 31 март г.Казань № 331

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе турында» 2011 ел, 26 декабрь, 1064 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе турында» 2011 ел, 26 декабрь, 1064 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 10 март, 204 нче; 2012 ел, 28 май, 425 нче; 2012 ел, 25 август, 737 нче; 2013 ел, 14 ноябрь, 874 нче; 2014 ел, 7 июнь, 389 нчы; 2016 ел, 13 август, 557 нче; 2016 ел, 30 декабрь, 1050 нче; 2017 ел, 27 ноябрь, 912 нче; 2018 ел, 12 май, 352 нче; 2018 ел, 29 октябрь, 956 нчы; 2019 ел, 15 гыйнвар, 2 нче; 2019 ел, 19 июль, 605 нче; 2020 ел, 28 апрель, 344 нче; 2020 ел, 15 сентябрь, 833 нче; 2020 ел, 9 ноябрь, 1001 нче; 2021 ел, 26 февраль, 102 нче; 2021 ел, 21 июль, 623 нче; 2021 ел, 27 ноябрь, 1139 нчы; 2022 ел, 25 июль, 714 нче; 2022 ел, 16 сентябрь, 1011 нче; 2022 ел, 16 декабрь, 1351 нче; 2023 ел, 4 июль, 789 нчы; 2023 ел, 27 сентябрь, 1191 нче; 2024 ел, 8 апрель, 240 нчы; 2024 ел, 2 июль, 492 нче; 2024 ел, 12 декабрь, 1135 нче; 2025 ел, 14 июнь, 429 нчы; 2025 ел, 25 декабрь, 1157 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе турындагы нигезләмәнең 7.4 пунктындагы уникенче абзацында «ведомство бүлекләрен билгеләнгән тәртиптә гамәлгә куя» сүзләрен «Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинеты белән килештереп, ведомство бүләкләрен (мактау билгеләрен, башка бүләкләүләрне) гамәлгә куя» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе структурасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Бу карарның 1 пунктындагы өченче абзацы 2026 елның 1 маеннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2011 ел, 26 декабрь, 1064 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 31 март, 331 нче
карары редакциясендә)

## Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек итү идарәсе структурасы

- Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек итү идарәсе башлыгы – Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы
  - Идарә башлыгы урынбасары – Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы урынбасары
    - Территориаль органнар (22 бүлек: Буа, Югары Ослан, Биектау, Чүпрәле, Зәй, Зеленодольск, Тәтеш, Казан шәһәре, Кама Тамагы, Кукмара, Лаеш, Мамадыш, Мөслим, Түбән Кама, Нурлат, Питрәч, Балык Бистәсе, Саба, Сарман, Теләче, Тукай, Чирмешән)
    - Күзәтчелек һәм автоматлаштырылган исәпкә алу бүлеге
  - Идарә башлыгы урынбасары – Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы урынбасары
    - Территориаль органнар (22 бүлек: Әгерже, Азнакай Актаныш, Аксубай, Алексеевск, Әлки, Әлмәт, Апас, Арча, Әтнә, Баулы, Балтач, Бөгелмә, Алабуга, Кайбыч, Лениногорск, Менделеевск, Минзәлә, Яңа Чишмә, Спас, Чистай, Ютазы)
    - Аттракционнарга күзәтчелек итү һәм урамда йөрми торган транспортны дәүләт контролендә тоту бүлеге
  - Оештыру-хокук һәм кадрлар эше бүлеге
  - Икътисадый анализ, эшчәнлекне һәм дәүләт сатып алуларын тәэмин итү бүлеге
  - Мобилизация эше буенча белгеч
  - Матбугат секретаре

---